Проект

2014 елда Зеленодоль муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе О. П. Дёгтеваның 2014 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МУ 2014 ел өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисабына бәяләмәсен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы бюджетының 2014 елгы үтәлеше турында хисап гавами тыңлауларда тикшерелде, дип билгеләп, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексына , «Россия Федерациясе җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 92 статьясына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 2 565 776 843,38 сум күләмендә, чыгымнар буенча 2 870 657 457,76 сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 304 880 614,38 сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

– 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары, әлеге Карарга 1 нче кушымта буенча;

– 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәре күләмнәре, әлеге Карарга 2 нче кушымта буенча;

– 2014 елда бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлү, әлеге Карарга 3 нче кушымта буенча;

– 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы, әлеге Карарга 4 нче кушымта буенча;

– 2014 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча чараларны тәэмин итүгә җирлек бюджетларыннан бюджетара трансфертлар, әлеге Карарга 5 нче кушымта буенча.

– 2014 елда бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр бүлү, әлеге Карарга 6 нчы кушымта буенча;

– 2014 елда граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү, әлеге Карарга 7 нче кушымта буенча;

– 2014 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү, әлеге Карарга 8 нче кушымта буенча;

– җирлекләр бюджетларыннан халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыруга, китапханәләрнең китапханә фондларын туплауга һәм аларның сакланышын тәэмин итүгә, ял вакытын оештыру һәм җирлекләрдә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруга бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 9 нчы кушымта буенча;

– 2014 елда муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне оештыруга җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 10 нчы кушымта буенча ;

– 2014 елда максатлы билгеләнештәге башка бюджетара трансфертларны җирлек бюджетларына бүлү, әлеге Карарга 11 нче кушымта буенча;

– 2014 елда Башлыкларны матди бүләкләүгә җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 12 нче кушымта буенча;

– муниципаль районнарның административ үзәкләре һәм шәһәр тибындагы поселоклар булган муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары җитәкчеләрен матди бүләкләүгә җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 13 нче кушымта буенча;

– 2014 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 14 нче кушымта буенча;

– 2014 елда архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте өлкәсендә җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 15 нче кушымта буенча ;

– 2014 елда юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү өчен җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар бүлү, әлеге Карарга 16 нчы кушымта буенча;

2. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга.

Зеленодольск муниципаль районы
Башлыгы,
ЗМР Советы рәисе А. В. Тыгин